Мирас

Сююмбика

11·12
1997

НА ТАТАРСКОМ И РУССКОМ ЯЗЫКАХ



Сабыйга

№ 11-12 (41-42) — 1997 ел.
(ноябрь-декабрь)

Балаларның
әдәби-нәфис журналы

ОЕШТЫРУЧЫЛАР:
«Сабыйга» журналы
редакциясе хезмәт коллективы,
Казан шәһәр хакимияте,
«Мирас» журналы редакциясе,
Татарстан белем министрлыгы

Баш мөхәррир
МИҢНӘХМӘТ СӘХАПОВ

Редакция советы:
Алла Айсина
Ришат Әбүбәкеров
Фаил Әхмәдиев
Шәүкәт Галиев
Мөнәвир Галимуллин
Фердинанд Галәмиев
Җәүдәт Дәрзаманов
Айрат Зарипов
Фирдәвес Зарифуллин
Фәрит Ишмаков
Аркадий Мельников
Роберт Миңнуллин
Флүн Мусин
Алия Сальникова
Лилия Сәхапова
Фарис Харисов
Вахит Хаков
Мөсәгыйт Хәбибуллин
Зөфәр Хәкимов
Әнәс Хәсәнов
Рәүф Хөснетдинов
Фәнис Яруллин

Т ы ш л ы к т а
Зөфәр Хәкимовның рәсемнәре.

«Сабыйга» балалар журналының индексы — **73954.** Аңа Татарстан Республикасының, Русия Федерациясе составында булган республикаларның, край һәм өлкәләрнең, БДБ составына кергән дәүләтләрнең һәм чит илләрнең элемтә бүлекләрендә чикләнмәгән күләмдә язылырга мөмкин. Журнал татар һәм урыс телләрендә нәшер ителә. Редакциянең адресы: 420066, Казан шәһәре, Чистай урамы, 5 йорт. Бәйләнешкә керү өчен телефон: ***(8432)*** **49-35-54.** Журналга язылу һәм аны тарату мәсьәләләре буенча 38-59-54 номерлы телефон аша мөрәҗәгать итәргә, ә басманың сыйфатына кагылышлы дәгъваларны исә 49-36-62 номерлы телефон ярдәмендә белдерергә мөмкин. Иганәчеләр өчен журналның исәп-хисап саны: **р/с № 049345602,** Россия Саклык банкының Татарстан Банкы 6672/0253. Корр. счеты № 600164503. Журнал идеясенең һәм исеменең авторы М. Җ. Сәхапов.
«Сабыйга» журналы Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 314 сан белән теркәлде. 1994 елның 1 июленнән бирле нәшер ителә.

Производствога бирелде 23.06.97 ел. Басарга кул куелды 13.11.97 ел. Форматы $84 \times 108^{1}/_{16}$. Күләме 2,0 (2,1) басма табак. 3,36 нәшер-хисап табак. Офсет ысулы белән басыла. Тиражы 7000 данә. Заказ Н-358. Вакпап студа ирекле бәя.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе. 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт.

© «Сабыйга», 1997 ел.

НОЯБРЬ

НОЯБРЬДӘ КҮК КҮКРӘСӘ — КАР МУЛ БУЛЫР.
КАРГА КЫЧКЫРСА — БУРАН ЧЫГАР.
ЙОЛДЫЗЛАР «СИКЕРСӘ» — САЛКЫН БУЛЫР.
НОЯБРЬ АЕНДА КЫШ КӨЗ БЕЛӘН БИЛ АЛЫША.



ДЕКАБРЬ

КАР ТИРӘН БУЛСА, ИКМӘК УҢАР.
КЫШ ӨЧ АЙ ЭЧЕНДӘ ЯШИ.
САЛКЫН БУЛСА, КАРГА БОРЫНЫН
КАНАТ АСТЫНА ЯШЕРӘ.
КЫШЫН КҮК КҮКРӘСӘ, КӨЧЛЕ ҖИЛ ЧЫГАР.

Урысчадан
ЛИЛИЯ СӘХАПОВА
тәрҗемәсе.

Рәссам ЗӨФӘР ХӘКИМОВ

НОЯБРЬ

ГРОМ В НОЯБРЕ — К БОЛЬШОМУ СНЕГУ.
ВОРОНА КРИЧИТ — К МЕТЕЛИ.
ЗВЕЗДЫ «ПРЫГАЮТ» — К ХОЛОДУ.
В НОЯБРЕ ЗИМА С ОСЕНЬЮ БОРЮТСЯ.

ДЕКАБРЬ

СНЕГ ГЛУБОК — ХЛЕБ ХОРОШ.
ЗИМА В ТРЕХ МЕСЯЦАХ ЖИВЕТ.
К СТУЖЕ ВОРОНА ПРЯЧЕТ НОС ПОД КРЫЛО.
ГРОМ ЗИМОЙ — К СИЛЬНЫМ ВЕТРАМ.

Художник ЗУФАР ХАКИМОВ

Сабыйга

№ 11-12 (41-42) — 1997 г.
(ноябрь-декабрь)

Детский литературно-художественный журнал

УЧРЕДИТЕЛИ:
Трудовой коллектив редакции журнала «Сабыйга», администрация г. Казани, редакция журнала «Мирас», Министерство образования Татарстана

Главный редактор
МИНАХМЕД САХАПОВ

Совет редакции
Ришат Абубакиров
Алла Айсина
Фаил Ахмадиев
Шаукат Галиев
Мунавир Галимуллин
Фердинанд Галямиев
Джавдат Дарзаманов
Айрат Зарипов
Фирдаус Зарифуллин
Фарид Ишмаков
Аркадий Мельников
Роберт Миннуллин
Флюн Мусин
Алия Сальникова
Лилия Сахапова
Фарис Харисов
Мусагид Хабибуллин
Вахит Хаков
Зуфар Хакимов
Анас Хасанов
Рауф Хуснутдинов
Фанис Яруллин

На обложке рисунки Зуфара Хакимова.

Индекс детского журнала «Сабыйга» **73954**. Подписка на журнал производится без каких-либо ограничений во всех отделениях связи Республики Татарстан, в областях, краях, республиках Российской Федерации, в государствах Ближнего и Дальнего Зарубежья. Журнал выходит на татарском и русском языках. Адрес редакции: 420066, г. Казань, ул. Чистопольская, 5. Тел.: ***(8432)* 49-35-54**; а/я № 227. По вопросам доставки и подписке обращаться по телефону 38-59-54, качества печати 49-36-62. Для спонсоров журнала: **р/с № 049345602** в Банке Татарстан Сбербанка России 6672/0253. Корр. счет № 600164503 в РКЦ НБ РТ, БИК 049205603. ИНН № 1654002150. Код ОКОНХ 87100, код ОКПО 12986213. Журнал «Сабыйга» зарегистрирован в Мининформпечати РТ. Свидетельство № 314. Выходит с 1 июля 1994 года.

Автор идеи и названия журнала М. Ж. Сахапов.

Сдано в производство 23.06.97 г. Подписано в печать 13.11.97 г. Формат $84 \times 108^1/_{16}$. Объем 2,0 (2,1). Учетн. изд. л. 3,36. Печатается офсетным способом. Тираж 7000 экз. Заказ Н-358. Цена договорная.

Типография газетно-журнального издательства. 420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© «Сабыйга», 1997 г.

Марат Әмирханов

Гүзәл дәү әнисенә кунакка кайтты.

— Сөбханалла, кул астына керерлек булып барасың түгелме соң, балам?— дип сөенде дәү әнисе.

— Мин ничек кул астында булыйм ди, менә ич, күр, яныңда басып торам,— диде кызчык.

Дәү әнисе оныгына карап шатланды. Мәмрәп пешкән бөрлегән шикелле иде ул. Тулы түгәрәк йөзле, калын иренле, итләч гәүдәле. Чуп-чуп итеп үбәсе генә килеп тора.

Гүзәл алып кайткан күчтәнәчләр белән иркенләп сыйландылар. Аннан соң чебиләрне ашатырга чыктылар. Ишек алды ямь-яшел чирәм иде. Йомшак. Ятып аунарлык кына. Көне дә матур. Күктә ник бер болыт әсәре күренсен. Кояш нурларын көлтә-көлтә сибә.

— Дәү әнием, иртәгә инешкә су коенырга төшәбез, җәме?— диде Гүзәл.

— Көне ничек була бит әле, балам.

Кыз җилкәләрен уйнатып алды:

— Әллә син күрмисеңме, дәү әнием, көн, әнә, ничек елмайган?

Җавап урынына әбисе кулындагы агач калак белән җим савытының читенә бәргәләргә тотынды. Шундук узыша-узыша чебиләр килеп җитте. Керештеләр ашарга, керештеләр тузынырга, «ә» дигәнче савытны ялт иттерделәр.

— Инкубатор чебешләре үткен була, шәһәр кызлары кебек,— дип көлемсерәде әбисе.

Рәссам СВЕТЛАНА ИБРАҺИМОВА

Сәер чебиләр

Дәү әбисенең бу шөгыле Гүзәлгә бик ошады. Үзе дә кат-кат чебиләрне җыйды. «Җитәр, балам, болай да бөтен җимне сосып бетерделәр»,— дип әбисе аны туктатырга мәҗбүр булды.

Иртәгесен Гүзәл йокыдан торуга тәрәзәгә бакты. Ә урамда яңгыр ява иде. Чак елап җибәрмәде.

— Борчылма, балам, иртәнге яңгыр төшкә туктый ул,— дип юатты аны әбисе.



Чыннан да, тиздән җил болытларны куып таратты. Ялтырап кояш чыкты. Ә кичкә таба әтиәнисе дә кайтып төште.

— Җә, кызым, авылда нинди һөнәргә өйрәндең?— дип сорады әнисе.

— Ишек алдына чыгыйк, шунда күрсәтермен.

Чыктылар.

— Әнием, син чебешләрне чакыра беләсеңме?— диде Гүзәл.

— Белмичә соң, мин авыл кызы ләбаса! Ти-ти-ти, ти-ти-ти...

Ләкин чебиләрнең хәбәрендә дә юк, тик чемченеп йөриләр. Шунда Гүзәл кулына калак алды да, җим савытының читенә бәргәләргә тотынды. Чебиләр аны сырып та алдылар.

— Менә ничек кирәк, әнием,— диде Гүзәл горурлык белән.

Марат Амирханов



Гүзель приехала в гости к своей бабушке.

— Боже мой, как выросла! Кажется, ты у меня под рукой уже не помещаешься?— радостно воскликнула бабушка.

— Ну, бабушка, как же я могу поместиться у тебя под рукой, видишь, я стою прямо рядом с тобой,— сказала девочка.

Бабушка не нарадуется, глядя на внучку. Гузель, как спелая ягодка. Круглолицая, губы пухленькие, сама крепенькая. Так и хочется ее все время чмокать.

Они вдоволь полакомились гостинцами, которые привезла Гузель. Потом вышли во двор кормить цыплят. Весь двор зеленый-презеленый, трава мягкая, хоть валяйся на ней. Да и день стоит прекрасный. На небе ни облачка. Солнце обильно льет свои лучи.

— Бабушка, завтра пойдем на речку купаться, ладно?— сказала Гузель.

— Каков еще будет день, внученька.

Девочка заиграла плечиками.

— Ты что, бабушка, не видишь что ли, вон как день-то улыбается.

Бабушка вместо ответа постучала деревянной ложкой по кастрюле с кормом. Тут же со всех сторон, обгоняя друг друга, стали сбегаться цыплята. Начали клевать, ссориться, и ахнуть не успели, как посуда опустела.

— Инкубаторские цыплята очень бойкие, как городские девчонки,— усмехнулась бабушка.

Странные цыплята

Гузели очень понравилось бабушкино занятие. И сама несколько раз созывала цыплят. «Хватит, доченька, и так скушали весь корм»,— вынуждена была сказать бабушка.

Гузель, проснувшись, сразу же кинулась к окну. На улице шел дождь. Она чуть не расплакалась. Бабушка ее успокаивала:

— Не переживай, внученька, утренний дождь недолгий, к обеду закончится.

Действительно, вскоре ветер разогнал тучи. Засверкало солнце. А к вечеру приехали родители. Мама спросила:

— Ну, доченька, чему ты научилась в деревне?

— Пойдем во двор, покажу.


Вышли.

— Мамочка, ты умеешь созывать цыплят?— спросила Гузель.

— А как же, я же деревенская! Ти-ти-ти, ти-ти-ти...

Однако цыплята даже ухом не повели, продолжали себе щипать траву. Тогда Гузель взяла деревянную ложку и начала бить по кастрюле с кормом. Цыплята разом ее обступили.

— Вот так надо, мамочка,— сказала Гузель с гордостью.



Художник СВЕТЛАНА ИБРАГИМОВА

Марат Әмирханов

ТАУДА

Дамирның чаңгылары бар. Яшел төстә. Мөһер дә сугылган. Фирма билгесе, ди. Дөрес, зурларныкы кебек ботинкага көйләнмәгән көйләнүен. Аның урынына, каешлары шәп. Киң, калын.

Менә шундый чаңгылар бүләк итте аңа Наил абыйсы. Ә ул спортчы. Һаман ярышларда йөри. Беркөнне телевизордан да күрсәттеләр. Елмаеп кул болгады. Дамир да әнисенең энесе Наил абыйсына охшарга тырыша. Көн саен иртән гимнастика ясый. Гәүдәсен дугадай арткы якка бөкрәйтеп, кулларын идәнгә тигезә ала инде хәзер. Шпагатка да утыра башлады. Аякларны алга-артка сузып утыру дигәнне аңлата шпагат.

Чаңгылары әйбәт, әйе. Тик шуу гына бик тәтеми. Әти-әнисе эштә. Үзе бакчага йөри. Шуңа күрә ял көнне көтеп ала. Вакыты булганда да, аны әлегә үзен генә җибәрмиләр.

Бүген әнисе алып чыкты.

Көн аяз. Кичә кичтән яуган кар өстендә кояш нурлары җемелдәшә. Әйтерсең лә, ишек алдына чыршы уенчыклары сипкәннәр. Ялык та йолык киләләр. Җил исми. Бары суык бабай гына бит очын чеметтерепчеметтереп ала.

Ишек алды чыр-чу килеп тора иде инде. Кайсы чана шуа, кайсы чаңгы таккан. Туп та тибәләр. Дамир тау янына китте. Һәр елны аларның ишек алдында кардан тау өяләр. Биек. Сикәлтәле.

Дамир килә-килешкә чаңгыларын күтәреп тауга менде.

Ул арада әнисе дә килеп җитте. Каян күреп алган, әле генә күрше апалар белән гөрләшеп тора иде.

— Улым, шуып төшә күрмә, имгәнерсең,— дип кычкырды.

Әнисенең сүзләрен ишеткәч, Дамир үзе дә курка калды. Өстән караганда тау тагын да текәрәк тоелды. Әнә, әнисенең түбәсе генә күренеп тора.

— Янында менәм,— диде әнисе,— урыныңнан кузгаласы булма.

Дамир әнисен тыңламады. Чөнки малайларның мыскыллы елмаюын күреп алган иде. Алар гүя, мәми авыз, әниеңнең итәгеннән аерыла алмыйсың, дип көләләр иде.

Чаңгыларын киде дә, аска очты. Күзләрен ачып җибәрсә, койма янында басып тора. Егылмаган да. Инде елмаю аның иреннәренә күчте.



Рәссам ЮРИЙ КАПИТОНОВ

Марат Амирханов

НА ГОРКЕ

Теперь у Дамира есть лыжи. Зеленые. И печать есть. Говорят, это фирменный знак. Правда, ботинки к ним не прилажены, как у взрослых. Зато ремни сногсшибательные — широкие, толстые.

Вот какие лыжи подарил ему дядя Наиль. А сам он спортсмен. Все время на соревнованиях. Однажды даже по телевизору его показывали. Улыбаясь, он помахал им рукой. Дамир старается во всем походить на маминого брата Наиля. Каждый день по утрам делает гимнастику. Уже научился, прогнувшись, доставать руками до пола. Даже на шпагат начал садиться. Шпагат — это значит сидеть, разбросав ноги взад и вперед.

Лыжи и вправду хороши. Лишь только кататься на них редко приходится. Родители на работе, сам в садике. Поэтому он с нетерпением ждет выходного дня. Даже, когда у него есть время, его пока одного не отпускают.

Сегодня он пошел с мамой. День был ясный. На выпавшем вчера снегу играют солнечные лучи. Будто рассыпанные по двору елочные игрушки, они то гаснут, то вновь загораются. Ни ветерка. Только морозец щиплет щечки.

Во дворе стоял уже шум-гам. Кто на санках, кто лыжи тащит. Даже мяч пинают. Дамир пошел на горку. Каждый год у них во дворе насыпают снежную гору. Высокую. С ухабами.

Дамир, держа свои лыжи, поднялся на гору. Тем временем подоспела мама. И когда она успела его увидеть, только что ведь стояла судачила с соседями.

— Сыночек, смотри не съезжай, ушибешься,— прокричала она.

Дамир и сам испугался, услышав тревожный мамин голос. Сверху гора казалась еще круче. Вон у мамы только макушка видна.

— Сейчас я к тебе поднимусь,— сказала мама,— пока не трогайся с места.

Но Дамир не послушался, потому что он заметил насмешливые улыбки мальчишек. Будто они говорили: «неженка, маменькин сыночек».

Он надел лыжи и полетел вниз. Когда он открыл глаза, то увидел себя уже стоящим возле забора. Даже не упал. Теперь и на его губах заиграла улыбка.

Перевод **НУРИИ БУРСАКОВОЙ.**



Художник ЮРИЙ КАПИТОНОВ



Рәссам ИЛДУС ӘҖЕМОВ

Марат Әмирханов

Мәхәббәт

Гүзәл бакчадан авырып кайтты. Салкын тигән, диделәр. Югыйсә, көннәр дә әйбәт иде. Җилле урында уйнаган, күрәсең. Ләкин үзе, табиб чакырабыз дигәч, бер дә яратмады.

— Мин иртәгә бакчага барырга тиеш, әнием,— диде ул.— Җиңү бәйрәменә хәзерләнәбез ич без.

— Өзлегеп китәрсең, кызым,— диде әнисе.

— Миңа олы чәшкәгә тутырып чәй яса. Күп итеп бал сал, җәме, әнием, мәтрүшкәне дә онытма. Тир чыгарлык булсын,— диде Гүзәл бик белдекле кыяфәттә.

— Боларны каян беләсең соң син, кызым?— диде әнисе.

— Ләйлә апа өйрәтте!

Ләйлә апа бакчада тәрбияче. Бик бала җанлы. Шуңа күрә балалар үз итә, ярата аны. Алар өчен тәрбияче апаларыннан да югарырак зат юк. Иң дөрес сүзләр — ул әйткән сүзләр, иң гадел гамәл — ул кылган гамәлләр.

Беркөнне Гүзәл әтисе белән әнисен шаккатырды бит! Әнисенә күлмәк сатып алганнар иде.

— Сиңа ошыймы, кызым?— дип сорады әнисе көзге каршында бөтерелә-бөтерелә.

Гүзәл бермәл дәшми торды, уйлана, янәсе. Аннан соң иреннәрен кыйшайтыбрак:

— Базар икътисады заманында, җә кем, чүпрәк-чапрак җыя инде,— диде.— Ләйлә апа акцияләр алган булыр иде.

... Әнисе чәйне кызы сораганча ясады. Ләкин Гүзәл төне буе саташып чыкты. Иртән дә хәле мактанырлык түгел иде. Шуңа да карамастан, торып киенергә тырышып карады. Көч-хәл белән яткырдылар.

Гүзәлнең көннәре ятакта үтте. Табиб тәкъдим иткән даруларның да әллә ни файдасы тимәде. Калын иреннәре кипшенеп катты. Күзләре моңсуланды. Йөзе агарды.

— Әнием,— диде ул өченче көнне кичкә таба.— Ләйлә апа белән сөйләшсәм, терелер идем. Телефоннан шалтыратыйк әле. Әнием, зинһар өчен!

Әнисе каршы килергә базмады. Күршеләрендә телефон бар иде. Шуларга керделәр.

Ләйлә апа нинди сүзләр әйткәндер, әнисе ишетмәде, әмма аның белән сөйләшкәч, Гүзәлнең күзләренә нур кайтты.

Иртәгесен ул бакчага китте.

Марат Амирханов

Любовь

Гузель пришла из садика больная. Сказали — простуда. И дни были вроде бы теплые. Видно, продуло где-то. Однако, когда собрались вызвать врача, она решительно запротестовала:

— Завтра я обязательно должна быть в садике,— сказала она.— Мы готовимся к празднику Победы.

— Но, доченька, ведь могут быть осложнения,— сказала мама.

— А ты сделай мне большую чашку чая с медом, не забудь положить туда душицу, чтобы пропотеть,— сказала Гузель тоном знатока.

— И откуда ты все это знаешь?— спросила мама.

— Лейла апа научила!

Лейла апа — воспитательница в детском саду. Всю душу отдает детям. И дети ее обожают, считают своей. Для них нет более высокого авторитета, чем их воспитательница. Все, что она скажет или сделает — все самое правильное и справедливое.

А однажды Гузель привела родителей в крайнее изумление. Маме купили новое платье.

— Тебе нравится, дочка?— спросила мама, крутясь перед зеркалом.

Гузель ответила не сразу, обдумывает, видите ли, ответ. Потом, презрительно скривив губы, заявила:

— В период рыночной экономики кто же тратит деньги на всякое тряпье. Лейла апа наверняка акции купила бы...

...Мама приготовила чай как просила дочка. Однако Гузель всю ночь бредила. Утром также нечем было похвалиться. Несмотря на это, она попыталась встать и одеться. Насилу обратно в постель уложили.

Дальнейшие дни Гузель провела в постели. Лекарства, прописанные врачом, не особенно помогали. Ее пухлые губки стали сухими. Глаза потухли, личико побледнело.

— Мамочка,— взмолилась она на третий день,— если бы я поговорила с Лейлой апой, я бы поправилась. Давай позвоним ей. Мамочка, пожалуйста!

Мама возражать не стала. У соседей был телефон. Пошли к ним. Какие уж слова говорила Лейла апа, мама не слышала, только после разговора с ней глаза у Гузель оживились.

Наутро она пошла в садик.

Перевод ***НУРИИ БУРСАКОВОЙ.***



Художник ИЛДУС АЗИМОВ



Рәссам ИЛДУС ӘҖЕМОВ

Марат Әмирханов

Велосипед

Дамирга велосипед алдылар. Дүрт тәгәрмәчле. Икесе зур, калын, һава тутырмалы. Икесе кечкенә. Ян-якка беркетелгән. Йөргәндә авып китмәскә.

Урамга Дамир ике тәгәрмәч белән чыкты. Малайлар уратып алды үзен. Бик кызыктылар. Кычкырткычы гына ни тора! Туп шикелле йомры бүксәсенә генә басасы; шунда ук «тү-тү», дип тавыш бирә. Мондый бүксәле велосипед башка берәүдә дә юк.

— Әти миңа Төркиядән велосипед алып кайта,— дип көнчеллеген басты Наил исемле малай.

— Бу «Олимпик»,— диде Дамир,— бик беләсең килсә, мондый велик Америкада да юк.

Наилнең авызы йомылды. Ә Дамир велосипедына атланды да, кычкырткычның бүксәсенә басты, юлдан китегез, янәсе, комачауламагыз. Элдертте генә. Үзенең авызы колагына җиткән. Шулай булмыйча, әнә ничә пар күз күзәтә аны. Сынатырга ярыймы соң?

Ишек алдын бер-ике мәртәбә әйләнгәч, янә дә кычкыртып малайлар янына килеп туктады.

— Мин дә утырып карыйм әле,— диде Наил.

— Мин беренче сорадым, әйе бит, Дамир, дип аңа каршы төште Хәлим. Наилнең дә бирешәсе килмәде.

— Юк, мин беренче,— дип Хәлимне этеп җибәрде.

— Әйдәгез чиратка салабыз,— дигән тәкъдим кертте күзлекле Илдар. Ул һаман шулай. Малайларның бәхәсен тыңлап-тыңлап тора да, кирәген генә әйтә дә куя. Аның белән килешмәү мөмкин түгел.

Ләкин бу юлы Дамир тәртәгә типте.

— Минем велик, үзем йөрим,— диде.

Аның кермәгән сукмагы, төртелмәгән почмагы калмады. Йөрде дә йөрде. Тик бераздан күңелсез була башлады.

Дамир чыр-чу килеп футбол уйнаган иптәшләре янына килеп туктады. Уенга чакыруларын көтте. Югыйсә, капкада берәү дә тупны аның кебек тота алмый.

Юк, чакырмадылар.

— Кем великта йөрергә тели?— дип үзе тәкъдим итәргә мәҗбүр булды. Тик ни хикмәт, аның бу сүзләренә дә игътибар итмәделәр. Дамирның күзләре дымланды. Бу минутта аның өчен коймага сөялгән шома, елгыр велосипедтан да кирәксез нәрсә юк иде.

Марат Амирханов

Велосипед

Дамиру купили велосипед. Четырехколесный. Два — больших с толстыми шинами, два — маленьких, прикрепленных с обеих сторон, чтоб не повалился на ходу.

На улицу Дамир вышел без маленьких колесиков. Мальчишки окружили его. С завистью. Один сигнал чего стоит. Нажмешь на круглую, как мяч, грушу, сразу же подаст звук: «Ту-ту». Ни у кого больше нет такого велосипеда с грушей.

— А мне папа из Турции привезет велосипед,— попытался погасить зависть в себе мальчик по имени Наиль.

— Это — «Олимпик»,— сказал Дамир,— если хочешь знать, такого велика даже в Америке нет.

Наиль замолк. А Дамир сел на новый велосипед и нажал на грушу, дескать, уходите с дороги, не мешайтесь. И рванул. У самого рот до ушей. Еще бы, вон сколько пар глаз на него смотрит. Разве можно подкачать?

Пару раз объехав двор, он, вновь просигналив, притормозил возле мальчишек.

— Дай и мне попробовать,— сказал Наиль.

— Я первый попросил, да ведь Дамир,— возразил Халим. Наиль тоже не хотел уступать.

— Нет, я первый,— сказал и оттолкнул Халима.

— Давайте установим очередь,— предложил очкарик Ильдар. Он всегда так. Послушает, послушает споры мальчишек, да и скажет свое слово. С ним не согласиться невозможно.

Однако, на сей раз Дамир сам заупрямился.

— Велик мой, сам буду кататься.

Он катался, катался. По всем дорожкам, заехал во все уголки двора. Но через некоторое время заскучал.

Дамир остановился возле шумно гонявших футбол приятелей. Ждал, что позовут играть. Ведь никто не умеет, как он ловить мяч в воротах. Нет, не позвали.

— Кто хочет на велике покататься,— вынужден был предложить он сам. Но что за чудо? Никто не обратил внимания даже на эти его слова. Глаза у Дамира увлажнились. В эту минуту для него не было ничего более ненужного, чем прислоненный к забору гладенький проворный велосипед.

Перевод **НУРИИ БУРСАКОВОЙ.**


Художник ИЛДУС АЗИМОВ

Төймәкәй

Ганс Христиан Андерсен



Төймәкәй аның алдында кулына черек агач кисәгеге тоткан килеш басып торды, аның башка фонаре юк иде.

— Рәхмәт сиңа, нәни валчыгым!— диде авыру карлыгач.— Мин шундый әйбәт җылындым! Тиздән мин тәмам терелермен һәм кабат кояшка таба очармын.

— Ах,— диде Төймәкәй,— хәзер шундый салкын, кар ява! Иң яхшысы, үзеңнең җылы урыныңда кал, ә мин сине карармын.

Төймәкәй карлыгачка таҗ яфракчыгына салып су һәм берничә арпа бөртеге китерде. Карлыгач ашап-эчеп алды һәм аннан соң ул кызга ничек итеп үзенең канатын күгән куагына бәреп яралатуы һәм шул сәбәпле, башка карлыгачлар белән җылы якларга очып китә алмавы хакында сөйләде.

Кыш килде. Бик салкын булды һәм ул җиргә егылды... Зур карлыгач бүтән берни дә хәтерләми, бирегә, җир асты юлына ничек эләгүе хакында да белми иде.

Карлыгач бөтен кышны җир асты юлында үткәрде, ә Төймәкәй исә аны тәрбияләде.

Сукыр тычкан да, кыр тычканы да бу хакта берни дә белмәделәр — чөнки алар кошларны бөтенләй яратмыйлар иде.

Яз җиткәч һәм кояш җылыта башлагач, Төймәкәй, карлыгач очып китә алсын өчен, түшәмгә сукыр тычкан ясаган тишекне ачты.

Урысчадан
ЛИЛИЯ СӘХАПОВА тәрҗемәсе.

(Дәвамы бар.)

Рәссам АЛЛА АЙСИНА



Дюймовочка

Ганс Христиан Андерсен

Дюймовочка стояла перед нею с куском гнилушки в руках — другого фонаря у нее не было.

— Спасибо тебе, милая крошка! — сказала больная ласточка.— Я так хорошо согрелась! Скоро я совсем поправлюсь и опять полечу на солнышко.

— Ах,— сказала Дюймовочка,— теперь так холодно, идет снег! Останься лучше в своей теплой постельке, а я буду ухаживать за тобой.

Дюймовочка принесла ласточке воды в цветочном лепестке и несколько ячменных зернышек. Ласточка попила и поела, а потом рассказала девочке, как она поранила себе крыло о терновый куст и не могла улететь вместе с другими ласточками в теплые края.


Пришла зима. Стало очень холодно, и она упала на землю... Больше ласточка уже ничего не помнила, и как попала сюда, в подземелье, она не знала.

Всю зиму прожила ласточка в подземелье, а Дюймовочка ухаживала за ней.

Ни крот, ни полевая мышь ничего не знали об этом — они ведь совсем не любили птичек.

Когда наступила весна и пригрело солнышко, Дюймовочка открыла дыру, которую проделал в потолке крот, чтобы ласточка могла улететь.

(Продолжение следует.)




Художник АЛЛА АЙСИНА

Каюм Насыйри



УНИКЕНЧЕ ТӘРБИЯ

Олуглардан берәү бер падишаһтан сорады: «Фәлән дәрвиш хакында ни әйтәсән? Бәгъзеләр аны хурлыйлар»,— диде. Ул падишаһ әйтте: «Мин тышкы яктан караганда гаеп күрмәймен, әмма эче, күңеле — билгесездер. Шуңа хөкем итә алмаймән»,— диде. Әй угыл, фәкать үзеңнең шигең белән генә: «Бу кеше фәләндер»,— дип, кеше өстенә гаеп исбат итмәк хатадыр. Моны явызлык диерләр, хәрам эшдер, моннан саклан.

(Рәссам ЗАҺИР ХӘКИМОВ)

Каюм Насыри

Книга о воспитании



НАСТАВЛЕНИЕ ДВЕНАДЦАТОЕ

Один царедворец спросил падишаха: «Что ты скажешь о дервише таком-то? Люди говорят о нем много плохого». Падишах ответил: «В его внешности нет ничего предосудительного, а что у него за душой, не видно. Я не могу судить о том, чего не вижу».

О сын мой, было бы ошибкой судить о человеке, полагаясь на свое недоверие. Это очень скверно. Избегай поспешных суждений.

Художник ЗАГИР ХАКИМОВ

Индекс 73954



Цена договорная